**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Байлангар авыл җирлеге башлыгы**

**карары**

**2022 елның 11 ноябре** **№22**

**«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставынының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 24 ноябренә 9 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы, 36а адресы буенча урнашкан Сазтамак башлангыч мәктәбе бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 24 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы, 36а адресы буенча урнашкан Сазтамак башлангыч мәктәбе бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,

- 1 төркем инвалидларыннан;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан;
- 18 яшькә кадәр 3 яки аннан да күбрәк баласы булган аналардан;
- 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокլы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала,

500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- зиратны карап тоту; материал сатып алу һәм койма кую;(проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- су кудыру башняларын карап тоту, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу; (проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, килешү буенча түләү);

- урам утларын карап тоту;(энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Сазтамак авылында кышкы-җәйге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»?

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Байлангар авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы И.Ф. Кәримуллин